| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|
| **ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК** |
| 27.04.2017 | № 175-пр |

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында**

“Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2009 елның 17 июлендәге № 172-ФЗ Федераль законга, “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге № 96 Карарына, “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карарына таянып, боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен расларга (беркетелә).

2. Әлеге боерыкның үтәлеген контрольдә тотуны министр урынбасары Ф.Ш.Мусинга йөкләргә.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
27 апрель 2017 ел № 175-пр
боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫНДА НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАРГА ҺӘМ НОРМАТИВ ХОКУКЫЙ АКТЛАР ПРОЕКТЛАРЫНА КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ ЭКСПЕРТИЗА ҮТКӘРҮ ТӘРТИБЕ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба - Министрлык) хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына, шулай ук Министрлык әзерләгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлар проектларына (алга - актлар, актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү процедурасын билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге № 883 карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә, әлеге Тәртипкә туры китереп, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән Методика (алга таба - методика) белән үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизага кергән актлар (актлар проектлары) Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналында (алга таба – Журнал) (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта) регистрацияләнә.

1.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада күрсәтелгән формада йомгаклама төзелә, анда түбәндәге белешмәләр чагылдырыла:

экспертизага бирелгән акт реквизитлары (акт проекты атамасы);

экспертиза үткәрү өчен нигез;

актта (акт проектында) коррупциоген факторлар булуы яки булмавы;

актның (акт проектының) коррупциоген факторлар булган конкрет нигезләмәләре;

коррупциогенлыкны бетерү өчен хокукый нормаларның формулировкаларын үзгәртү яки аерым нормаларны төшереп калдыру өчен тәкъдимнәр.

## 2. Министрлык актларына коррупциягә каршы экспертиза

2.1. Министрлык актларына коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның хокук идарәсе тарафыннан уздырыла. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен җаваплы хокук идарәсе белгече (алга таба – җаваплы зат) Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры (алга таба – Министр) боерыгы белән билгеләнә.

2.2. Министрлык актларына коррупциягә каршы экспертиза аларны Министрлыкның структур бүлекчәләре куллануына мониторинг үткәргәндә коррупциоген факторлар ачыкланган очракта, шулай ук, актларда коррупциоген факторлар барлыгы турында мәгълүмат теләсә нинди ысул белән алынган очракта да җаваплы зат тарафыннан үткәрелә.

Коррупциягә каршы экспертиза көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив хокукый актларга үткәрелми.

2.3. Актларны җаваплы зат тиешле мәгълүмат алынган көнне яисә Министрлы җитәкчелеге актны юллаган көнне Журналда регистрацияли.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза акт Журналда регистрацияләнгәннән соң ун көн эчендә үткәрелә.

Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре йомгаклама буларак формалаштырыла, ул әлеге Тәртипнең 1.4 пунктына туры китереп җаваплы зат тарафыннан төзелә һәм Журналда чагылдырыла.

Актка коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре турында актны экспертиза юллаган затка йомгаклама төзелгәннән һәм имзаланганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

2.5. Актта коррупциоген факторлар барлыгы турында йомгаклама төзелгәннән һәм җаваплы зат тарафыннан имзаланганнан соң бер эш көненнән

дә соңга калмыйча Министрга юллана.

2.6. Актта коррупциоген факторлар барлыгы турында йомгаклама нәтиҗәләре буенча Министр аңа үзгәрешләр кертү ихтыяҗы турында карар кабул итә яисә көчен югалткан дип таный.

2.7. Әлеге актны чыгару инициативасы белән чыккан структур бүлекчә Министр әлеге Тәртипнең 2.6 пунктында күрсәтелгән карар кабул иткәннән соң өч көн эчендә Министрлык акты проекты әзерли һәм аны коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затка юллый. Андый проектка коррупциягә каршы экспертиза әлеге Тәртипнең 3 бүлегенә туры китереп үткәрелә.

## 3. Министрлык актлары проектларына, шулай ук, Министрлык тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза

3.1. Министрлык актлары проектларына, шулай ук, Министрлык тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы актлары проектларына (алга таба – актлар проектлары) коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның хокук идарәсенең җаваплы заты тарафыннан хокукый экспертиза үткәргәндә үткәрелә.

3.2. Актлар проектлары коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Министрлыкның структур бүлекчәсенең проектны әзерләү өчен җаваплы заты тарафыннан юллана.

3.3. Кергән актлар проектлары кергән көнне җаваплы зат тарафыннан Журналга теркәлә.

Коррупциягә каршы экспертиза проект регистрацияләнгәч 10 көн эчендә үткәрелә.

3.4. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре җаваплы зат тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.4 пунктына туры китереп төзелгән йомгаклама буларак формалаштырыла һәм Журналда чагылдырыла.

Коррупциоген факторлар булуы турында йомгаклама төзелгән көнне проектны юллаган структур бүлекчәгә тапшырыла.

3.5. Коррупциоген факторлар булса, проектны әзерләгән структур бүлекчә, йомгакламаны алгач та өч көн эчендә проектны эшләп бетерә һәм кабатлап коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы затка юллый.

3.6. Коррупциягә каршы экспертиза, эшләнеп беткән проект алынганнан соң өч көн эчендә, әлеге Тәртипнең 3.4 һәм 3.5 пунктында каралган тәртиптә кабатлап үткәрелә.

## 4. Министрлык актларына һәм актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза

4.1. Рәсми бастырылган һәм «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында (http://mzio.tatarstan.ru/ (алга таба - сайт) урнаштырылган Министрлыкның рәсми чыгарылган норматив хокукый актлары, Министрлык тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып тора.

4.2. Министрлыкның норматив хокукый акты проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, Министрлыкның аны әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе норматив хокукый акт проектын карау өчен Министрлыкның хокук идарәсенә юллый. Хокук идарәсенең җаваплы заты карау өчен акт кергән эш көне эчендә акт проектын, эксперт бәяләмәләрен юллау адресларын (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр кабул итү башлану һәм тәмамлану даталарын күрсәтеп, сайтка урнаштыра.

4.3. Сайтка урнаштырылган актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү срогы биш эш көненнән дә кимрәк була алмый.

4.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка кергән йомгаклама (алга таба – йомгаклама) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары ведомствоара электрон документ әйләнеше бердәм системасында теркәлә һәм карау өчен Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә юллана.

4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр тәкъдим итү характерында була һәм алынганнан соң 15 көн эчендә Министрлык тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затларга карау нәтиҗәләре буенча нигезле җавап юллана, бәяләмәдә коррупциоген факторлар турында мәгълүмат булмавы яки ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысуллары турында мәгълүмат булмау искәрмә булып тора.

4.6. Акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә

ачыкланган коррупциоген факторлар акт проектын әзерләп бетерү стадиясендә әзерләүчеләр тарафыннан төзәтелә.

4.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә бәян ителгән кимчелекләр бетерелгәч һәм тәкъдимнәр исәпкә алынгач, Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җавапды бүлекчәсе акт проектын кабат карап чыгу өчен, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне кушып, Министрлыкның хокук идарәсенә тапшыра. Кабаттан карап чыга өч көн эчендә башкарыла.

4.8. Актта коррупциоген факторлар ачыкланса, Министрлыкның әлеге актны әзерләгән бүлекчәсе бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә Министрлыкта регистрацияләнгәннән соң өч көн эчендә актка үзгәрешләр кертү яки аны көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

4.9. Министрлык актларында һәм Министрлык әзерләгән актлар проектларында коррупциоген факторлар булуы турында коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре белән Министрлык килешмәсә, законнарда күрсәтелгән тәртиптә күрсштелгән актларны (актлар проектларын), коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен, шул исәптән, бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен теркәп, үзенең ризасызлыгын нигезләгән ачыклау язуы белән бергә, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына юллый.

4.10. Әзерләүче Министрлык әзерләгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына кертелүче Министрлык тарафыннан әзерләнгән федераль законнар проектларына, Татарстан Республикасы законнары проектларына, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булуы турында коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре белән, шул исәптән, бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән дә, килешмәсә, күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын карау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра.

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында
норматив хокукый актларга
һәм норматив хокукый актлар проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә
1 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен кергән
норматив хокукый актлар
һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу
журналы

| Экспертизага акт (акт проекты) керү датасы | Актны (акт проектын) биргән структур бүлекчә | Акт (акт проекты) атамасы | Коррупциоген нормалар булу/булмау | Йомгаклама төзү датасы | Искәрмәләр (кабат экспертиза үткәрү турында мәгълүмат, кабат экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча йомгаклама төзү датасы) (актлар проектларына мөнәсәбәтле) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгында
норматив хокукый актларга
һәм норматив хокукый актлар проектларына
коррупциягә каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә
2 нче кушымта

Коррупциягә каршы экспертиза йомгакламасы

______________________________________________________________________
(норматив хокукый акт реквизитлары яки норматив хокукый акт проекты атамасы)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

"Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2009 елның 17 июлендәге № 172-ФЗ Федераль законга, "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге № 883 карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә, "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге № 96 Карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасына таянып, коррупциогенных факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатында коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Проектта коррупциоген нормалар булуы яки булмавы:
______________________________________________________________________
Акт проектының коррупциоген нормалар булган конкрет нигезләмәләре:
______________________________________________________________________
Формулировкаларны алмаштыру яисә коррупциогенлыкны бетерү өчен аерым нормаларын төшереп калдыру буенча тәкъдимнәр:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
_
Җаваплы зат ______________________________________________________